ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Канаш торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2025 елның 18 ноябре №1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33 - ФЗ номерлы Федераль законның 45 һәм 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Канаш торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар иттем:

1. Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Канаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, ташлама алучылардан тыш, 2026 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына, Канаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,<br>
Югары Ослан муниципаль районының<br>
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков